ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДҮСМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Молодежная, д.17, с. Дюсьметьево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422150

Яшьлек ур., 17 нче йорт, Дүсмәт авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422150

тел.(факс): (85563) 2-55-19; e-mail: Dusm.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Постановление | Карар

“22 ” декабрь 2017 ел | № 18

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы гербы күчермәсе белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитетының герб мөһере үрнәген раслау турында

Эш башкаруны тәртипкә салу, Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитеты документларын ышанычлы тәңгәлләштерүне тәэмин итү максатларында, Мамадыш районы прокурорының дәүләт символлары турындагы закон бозуларны бетерү турындагы 15 августындагы № 02-08-03-2017 тәкъдиме, Мамадыш муниципаль районы Советының 2017 елның 13 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге гербын куллану турында» № 6-19 карары нигезендә **карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы гербы күчермәсе белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитетының герб мөһере оттискын расларга.(1 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 22 декабрендәге 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегендә мөһерләрне һәм штампларны исәпкә алу, әзерләү, куллану, саклау һәм юк итү тәртибе турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- мөһерләрне, штампларны һәм фирма бланкларын куллану;
- аларны куллануны, тиешле саклауны һәм саклануын контрольдә тоту.

2.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә..

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе /О.Н.Павлов/

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы гербы күчермәсе белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитетының герб мөһере оттискы

